

Быел Мордовия Республикасы кадетлар хәрәкәте 25 еллык юбилеен билгеләп vтте. Кадетлык - боек илебез тарихынын моһим олеше. Кадет корпусларында тәрбияләнvчеләр гомер-гомергә милләтнен горурлыгы булдылар, vзләрен хәрби сәнгатьтә генә тvгел, мәдәниятта, фәндә, ижтимагый тормышта да кvрсәттеләр.
2 декабрьдә тобәктә кадетлар хәрәкәтен булдыру башында торучыларны һәм анда катнашучыларны Мордовия башлыгы Артём Здунов котлады. - Барыннан да элек мин укытучыларны, хокук саклау блогы житәкчеләрен - республикада кадетлар хәрәкәтен оештыруга һәм vстерvгә катнашы булганнарнын барысын да котлыйсым килә. Аларнын игътибары, хезмәттәге фидакарьлеге нәтижәсендә кадетлар хәрәкәте vсә, белем һәм кvнекмәләр тапшырыла, - диде Артём Здунов.
Бvген хәрәкәттә 4500 гә якын кадет катнаша, әзерлекнен 13 юнәлеше бар – дингез кадет сыйныфлары һәм кадет-ушаковчылар, казак кадет линиясе, Девятаев исемендәге «Высота» мәгариф vзәгендә беренче очучы кадет сыйныфы. Бу хәрәкәткә коч структуралары житәкчеләре актив кушылды.
- Чирек гасыр эчендә Оборона Министрлыгы, Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы һәм башка коч структуралары уку йортларына 166 кадет керде. Без бvген алдынгы махсус хәрби операциядә дә vз бурычларын намус белән vтәvчеләр, тылда эшләvчеләр, безнен жинvгә олеш кертvчеләр белән горурланабыз. Аларнын Ватанга туг-рылыгы, ватанпәрвәрлеге ил мондый яклауга мохтаж булганда читтә калырга момкинлек бирмәде. Безнен очен кадет хәрәкәтен тәмамлаган һәр кешенен жәмгыятебезнен лаеклы әгъзасы булуы бик моһим, - ди Артём Здунов.
Юбилей датасы унаеннан республика башкаласында һәм районнарында зур кадетлар атналыгы узды. Ул vзенә кызыклы чаралар, ярышлар кертте. 26 нчы лицей кадетларынын сафта янадан ин яхшылар булулары символик мәгънәгә ия. III дәрәжә Мордовия Республикасы Дан орденын Артём Здунов хезмәт ветераны, 26 нчы лицейны 35 ел житәкләгән, РМ халык укытучысы Юрий Митрофановка тапшырды.
Мордовия башлыгы шулай ук «Объективта кадетлык» фотокvргәзмәсен, кадетлар хәрәкәте тарихы турында презентацияне карады һәм «Мордовия Республикасы кадетлар хәрәкәте елъязмасы»нда истәлекле язма калдырды.